ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 сентября 2020г. № 4389

**Башкарма комитетның «Муниципаль норматив хокукый актларны «ҮзәклӘштерелгән китапханәләр системасы» дәүләт мәдәният учреждениесенә бирү турында» 2006 елның 17 июлендәге 2489 номерлы карары үз көчен югалтуны тану хакында**

«Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль норматив хокукый актларны «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» дәүләт мәдәният учреждениесенә бирү турында» 2006 елның 17 июлендәге 2489 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов